ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

12 05 2026 г. № 499

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категориядәге гражданнарга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2016 елның 04 маендагы 874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 61 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 75 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категориядәге гражданнарга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2016 елның 04 маендагы 874 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 пунктындагы 3, 4, 5, 6, 19, 20 абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

карарның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп тулыландырырга:

«2026 елның 1 сентябреннән Түбән Кама муниципаль районы белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган түбәндәге категориядәге гражданнарга баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең тулы ставкада эшләүче хезмәткәр һәм шул ук вакытта ата-ана булганнарга.»;

әлеге карарның кушымтасы нигезендә, карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М. Офицеровага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Латыйпов

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 12 гыйнвар 49нчы номерлы карарына кушымта

Кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама му-ниципаль районы Башкарма комитеты ка-рары белән расланды
04.05.2016 № 874

Түбән Кама муниципаль районы белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категориядәге гражданнарга балаларын караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү
Тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категориядәге гражданнарга ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы балаларга мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә йөрүче балаларны караган һәм тәрбияләгән гражданнарга ата-ана түләвенең бер өлешен билгеләү һәм түләү механизмын билге-ли (алга таба – компенсация).

1.2. Аерым категориядәге балалы гражданнарга ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү тәртибе мәктәпкәчә һәм башлангыч мәктәп яшендәге балалар өчен белем бирү оешмаларына (башлангыч мәктәп – балалар бакчасы) кагыла.

1.3. Компенсация Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә гражданнарның түбәндәге категориясенә билгеләнә һәм түләнә:

- I һәм II группа инвалид ата-анага;

- Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган баланың (балаларның) ата-анасына;

- баланың (балаларның) ата-анасына, аның икенче ата-анасы (законлы вәкиле) Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы яисә «Үзәк» гаскәрләре

төркемчәсе берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт узучы баланың (балаларның) ата-анасына;

- «БАРС» («Илнең Хәрби армия резервы») ирекле отрядларында махсус хәрби операция барышында ирекле рәвештә хәрби бурычларны үтәгән икенче ата-анасы (законлы вәкиле) баланың (балаларның) ата-анасына;

- Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган граждан сыйфатында махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган), Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә «Алга» һәм «Тимер», Татарстан Республикасында төзелгән яисә «Үзәк» гаскәрләре төркемчәсе берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт узучы, шулай ук «БАРС» («Илнең Хәрби армия резервы») ирекле отрядларында махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче баланың (балаларның) ата-анасына;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Идарәсе хезмәткәре, махсус исеме булган һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсендә хезмәт узучы ата-анага;

- ата-анага -хәрби хәрәкәтләр ветеранына;

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының төп эш урыны буенча мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә эшләүче хезмәткәр ата-анага.

1.4. Компенсация әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән аерым категориядәге гражданнар арасыннан белем бирү программасын гамәлгә ашыручы тиешле муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениесе (алга таба – Учреждение) белән шартнамә төзегән һәм баланы караган һәм тәрбиягән өчен (алга таба-мөрәҗәгать итүче) ата – ана түләвен керткән законлы вәкилгә (ата-анага, уллыкка алучыга, опекунга) билгеләнә һәм түләнә.

Компенсация шулай ук әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының 3, 4, 5, 6 абзацларында күрсәтелгән, теркәлгән никахта торучы һәм үз иренең баласының (балаларының) биологик ата-анасы булмаган гражданнарга билгеләнә һәм түләнә».

1.5. Компенсация күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К3 = Ф - К1 - К2$$ , монда:

К3 - аерым категориядәге гражданнарның өстәмә компенсация күләме;

Ф - Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланган ата-ана түләве күләме чикләрендә мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә мәгариф учреждениесендә баланы караган һәм тәрбиягән өчен алына торган ата-ана түләве күләме;

К1 - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 елның 18

гыйнварындагы 9 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләп чыгарылган компенсация күләме.

К2 - мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә баланы караган һәм тәрбиягән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә Түбән Кама Башкарма комитеты «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 27.09.2013 ел, № 1376 карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән компенсация күләме".

1.6. Барлык компенсацияләрнең гомуми суммасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә карау һәм тәрбияләү өчен түләнә торган ата-аналар түләвеннән артмаска тиеш.

## II. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать итүче Түбән Кама муниципаль районында яшәү урыны буенча компенсацияне кабул итү һәм түләүгә билгеләү буенча вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

- компенсация билгеләү турында гариза;
- Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы турындагы белешмә;
- инвалидлыкны билгеләүне раслаучы документлар (I һәм II төркем инвалид ата-ана өчен);
- никахлашу турында таныклык күчермәсе (әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының 3, 4, 5, 6 абзацларында күрсәтелгән гражданнар өчен);
- мәктәпкәчә мәгариф учреждениесенә йөрүче (йөрүче) һәм аның (аларның) биологик ата-анасы булмаган баланың (балаларның) ата-анасы белән теркәлгән никахта торучы икенче ата-ананың (законлы вәкилнең) яисә гражданның махсус хәрби операциядә катнашу фактын раслый торган белешмә;
- эш урыныннан белешмә һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының махсус исеме булуын раслый торган документ (Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе хезмәткәрләре өчен);
- хәрби хәрәкәтләр ветераны таныклыгының күчермәсе;
- әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә расланган форма буенча бирелгән ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация алу хокукы турында эш урыныннан (муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре өчен) белешмә.

Вәкаләтле органның компенсация бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләре булганда, мөрәҗәгать итүче югарыда күрсәтелгән документларның барысын да яисә өлешләрен тапшыру бурычыннан азат ителә.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә банк аша компенсация алганда паспортын (аны алмаштыручы документны), мәктәпкәчә мәгариф учреждениесе белән шартнамә төзегән лицевой счет номерын күрсәтә.

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнары булган баланың (балаларның) ата-анасына каралган компенсация билгеләү өчен, Татарстан Республикасында төзелгән, яисә «Үзәк» гаскәрләре группировкасының берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт узучы, «БАРС» («Илнең Хәрби армия резервы») ирекле отрядларында махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче граждан, яисә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) икенче ата-анасы (законлы вәкиле), мөрәҗәгать итүче компенсация билгеләү турында гаризаны Түбән Кама муниципаль районында компенсация түләүне кабул итү һәм билгеләү буенча вәкаләтле органга бала (балалар) йөри торган мәктәпкәчә мәгариф учреждениесе аша тапшыра. Компенсация билгеләү турында кергән гаризаларны мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре гомумиләштерү һәм җибәрү өчен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә белем бирү идарәсенә, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарыннан алынган белешмәләр белән бергә Түбән Кама муниципаль районында компенсация түләүне кабул итү һәм билгеләү буенча вәкаләтле органга җибәрәләр.

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарыннан тапшырылган белешмәләрдә әлеге абзацта күрсәтелгән ата-ана категориясенә карата мәгълүмат булмаган очракта, мөрәҗәгать итүче гаризага өстәмә рәвештә икенче ата-ананы мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру турында чит шәһәр хәрби комиссариаты органнары белешмәсен дә кушып бирә.

Хәрби хәрәкәтләр ветераны ата – анага каралган компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать итүче компенсация билгеләү турында гариза һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераны таныклыгының күчермәсен бала (балалар) йөри торган мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе аша Түбән Кама муниципаль районында компенсация түләүне кабул итү һәм билгеләү буенча вәкаләтле органга тапшыра.

Компенсация билгеләү турында гаризаларны, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре Түбән Кама муниципаль районында компенсация түләүне кабул итү һәм билгеләү буенча вәкаләтле органга гомумиләштерү һәм җибәрү өчен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә мәгариф идарәсенә җибәрәләр.

2.2. Гариза һәм документлар почта аша җибәрелергә мөмкин. Гаризаны һәм документларны почта аша җибәрү вәкаләтле оешма фактын һәм аны алу датасын расларга мөмкинлек бирә торган ысул белән башкарыла.

2.3. Идарә ай саен хисап аеннан соң килә торган 2 нче числога кадәр вәкаләтле органга компенсация бирү өлешендә вәкаләтле органның Идарә белән мәгълүмати хезмәттәшлеге турындагы килешүдә билгеләнгән таләпләр нигезендә электрон рәвештә мәгълүмат тапшыра.

2.4. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә вәкаләтле орган гариза барлык кирәкле документлар белән теркәлгән көннән алып 10 көн эчендә компенсация билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту

турында карар кабул итә һәм тиешле карарны мөрәҗәгать итүчегә күрсәткән (хат, СМС-хәбәр, электрон почта аша, ә мөрәҗәгать итүчеләр өчен-дәүләт һәм муниципаль порталлардан теркәлгән файдаланучылар өчен) Татарстан Республикасы хезмәт күрсәтүләре - шәхси кабинет аша хәбәр итү юлы белән җиткерә.

2.5. Компенсация билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр булып:

- әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;
- гамәлдә булу вакыты чыккан документларны тапшыру (күрсәтү) ;
- закон таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән документларны тапшыру;
-мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карарында каралган компенсацияне алучы булып саналмый.

2.6. Компенсация түләүне туктату өчен нигезләр булып:

- ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация алу хокукын югалту, шул исәптән инвалидлыкны бетерү;
- мәктәпкәчә мәгариф учреждениесе хезмәткәрләре өчен вазыйфасыннан азат итү;
- мәгариф оешмасының алмашынуы;
- ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү;
- мөрәҗәгать итүченең үлеме;
- Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы яисә берләшмәләрдә һәм «Үзәк» гаскәрләре группировкасының хәрби частьләрендә;
- «БАРС» («Илнең Хәрби армия резервы») ирекле отрядларында махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар өчен ирекле формалашуда булуны тәмамлау;
- Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсе хезмәткәре белән контрактны туктату яки өзү.

2.7. Техник мөмкинлекләр булганда компенсация бирү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль яклау (ярдәм) чараларын, социаль хезмәт күрсәтүләрне билгеләү һәм күрсәтү процессларын, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне гамәлгә ашыруга төп таләпләрне раслау турында» 2024 елның 3 маендагы 564 номерлы карары нигезендә электрон рәвештә башкарыла.

Күрсәтелгән очракларда компенсация бирү «Социаль өлкәдә булышлык үзәкләштерелгән санлы платформа» дәүләт мәгълүмати системасыннан яисә дәүләт хакимияте органнарының (дәүләт органнарының), җирле үзидарә органнарының, Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды, шулай ук дәүләт

хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларның мәгълүмати системаларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла

III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Мөрәҗәгать итүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар булган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.2. Идарә әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы.

3.3. Вәкаләтле орган документларның дөреслегенә һәм тапшырылган белешмәләрнең дөреслегенә шик туган очракларда мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган белешмәләрне бирелгән вәкаләтләр чикләрендә өстәмә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

3.4. Компенсация суммасы мөрәҗәгать итүченең банк счетына күчерелә.

3.5. Банк счетларына күчерү бөтен исәп-хисап ае дәвамында башкарыла.

3.6.Гражданнар компенсация түләүне туктатуга китерә торган хәлләр башлану турында вәкаләтле органга мондый хәлләр башланганнан соң бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

3.7. Түләүне туктатуга китерә торган хәлләр килеп чыкканда, түләү тиешле хәлләр башланган айдан соң килә торган айдан туктатыла.

3.8. Белә торып дөрес булмаган белешмәләр белән документлар тапшыру, өстәмә компенсация алу хокукына йогынты ясый торган белешмәләрне яшереп калдыру нәтиҗәсендә артык түләнгән компенсация суммалары мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәнең казначылык счетына ирекле рәвештә кертелә, ә мөрәҗәгать итүче баш тарткан очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә түләтелә.

3.9. Алучыга тиешле һәм Идарә гаебе белән вакытында алынмаган компенсация  суммасы узган вакыт өчен нинди дә булса срок белән чикләүсез түләнә.

3.10. Мөрәҗәгать итүче вафат булган очракта, аңа исән чагында түләнмәгән исәпләнгән компенсация суммасы мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас итеп алына.

3.11. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

Түбән Кама муниципаль районы белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категориядәге гражданнарга балаларын караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү Тәртибенә кушымта

(Формасы)

Ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация хокукы алуга белешмә

_______________________________________________________________ бирелә
(тулысынча Ф.И.А. исеме )

ул (ул) чыннан да __________________________ (төп эш урыны буенча эшкә кабул итү датасы) төп эш урыны буенча

_________________________________________________________________________
(муниципаль учреждение исеме)

вазыйфасында ________________________________________________эшли,
(вазыйфа исеме)

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында” 2016 елның 04 маендагы 874 номерлы җитәкчесе тарафыннан расланган карары белән ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация алуга хокук бирә.

Белешмә таләп итү урыны буенча күрсәтү өчен бирелгән.

Учреждение җитәкчесе _________________/_________/
(Ф.И.А., имзасы)

«_____»_____________20___ ел
П.У.